СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

23 август, 1997ел.
ШИМБӘ

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 94 (8106) | Бәясе билгеләнгәнчә

Тән азыгы - икмәк,
җан азыгы гыйлем
һәм мәгърифәттер.
(К.Насыйри).




## Минипарк булачак

Норлатның азык-төлек базары ишегалдында төзүчеләрнең ыгы-зыгы килеп яңа төзелеш участогын барлыкка китерүләренә норлатлылар игътибар итми калмагандыр, мөгаен. Яңа байлар кибет яки коттедж саладыр дип, кул селтәүчеләр дә бардыр. Ләкин юк, мондый нәтиҗәләр ясарга [illegible]кмыйк, бирелә МПП [illegible]еләре халык өчен минипарк төзүгә нигез салды. Аны хуҗалыкара производство предприятиесе алып бара. Проект-смета документацияләргә күз салганда, район җитәкчелеге бу объектка шактый гына акча кертергә ниятли: минипаркта кыйммәтле төзелеш материаллары кулланып ял зонасы, фонтан, балалар мәйданчыгы төзеләчәк. Бизәлешен тиешле дәрәҗәдә күркәм итү өчен дә аерым төрле чаралар каралган.

## Көнкүреш йорты янә эшли

Шикәрчеләр поселогындагы көнкүреш йорты заманында гөрләп эшләде. Өс киемнәре, бүрекләр тегелә, аяк киемнәре ремонтлана иде биредә. Поселок халкы кем әйтмешли, муеннан эшкә күмә иде көнкүрешчеләрне.

Иде. Иде... Аннан соң берничә ел бу йортның исеме җисеменә туры килмәде. Ниһаять, көнкүрешчеләр бу бинаны яңадан «торгызырга» ниятләделәр. Хәзер биредә җиңел өс киеме тегүгә, кием ремонтлауга заказлар кабул ителә башлады. Шулай ук чәчтараш цехы да эшләячәк.

## Аяк киемегез «сынатса»

Аяк киемегезгә ремонт таләп ителгәндә кемгә мөрәҗәгать итәсез? Бу эш белән өйләрендә торып шөгыльләнүче аерым осталарга, дигән җавап ишетерсез. Әмма бит әле андыйларны эзләп табасы бар. Ә көнкүреш хезмәте? РПУның (хәзер ул «Надежда» дәүләт предприятиесе) аяк киемнәренә теләсә нинди ремонт үткәрү өчен бөтен шартлары булган бина күптән буш тора бит.

Шөкер, күптән түгел бу цех янә эшли башлады. Аяк киемегез «сыната» башласа бирегә, Г.К.Гыйматдинов урамындагы 79 йортка урнашкан аяк киемнәре ремонтлау цехына мөрәҗәгать итегез.

# Кырлар кала бушап, амбарлар тула шыплап



«Киекле» хуҗалыгы шоферы Вазыйх Мортаза улы Хәлитовны фотохәбәрчебез Н.АЗИЗОВ бодай кырында рәсемгә төшереп алган иде.

Өч дистә елдан артык шофер булып эшләгән чорда Вазыйх абыйга машинаның да төрлесен йөртергә, йөкләрнең дә төрлесен ташырга туры килде. Әмма нарядның ниндие генә бирелсә дә, аны җиренә җиткереп башкаруны намус эше саный ул. Шулай да урак өсте җитәр алдыннан аерым бер дулкынлану кичерә, чөнки машинасында йөкнең иң кадерлесен ташыр көннәр җитүен белә. Шуңа күрә КамАЗының әрҗәсен бөртек коелмаслык иттереп ныгытып чыга, машинасының бүтән өлешләрен дә кат - кат күздән кичерә: вакытның сәгате - минуты кадерле чакта комбайннар да техника көтеп кырда туктап торырлык, дәүләткә озатыласы ашлык та ындырда кызышып ятарлык булмасын дип тырыша. Бу чорда үзе дә алны - ялны белми эшли ул. Менә быелгы уракта Вазыйх ага кырдан ындыр табагына 5 мең центнерлап ашлык ташыды. Болай иртән иртүк, ә комбайннар кырга чыга алмаган көннәрдә көне буе элеваторга илткән ашлыгы да 2 мең центнердан артык инде.

## КИЛЕП ЯУСА ДА БЕР БОЛЫТ...

Берничә көн рәттән «еламсырап» торган көн, сишәмбе көнне бөтенләй «чишелде»: төньяктан килеп яуган бер болыт яңгырны чиләкләп диярлек актарды. «Иртәгә эш тулысынча тукталачак икән инде», дип көенгәннәр иде җитәкчеләр. Иртән ялт итеп чыккан кояш, дымны «ашаучы» җил бөтен планнарны үзгәртте дә куйды. 2 трактор гадәттәгечә җирне туңга сөрергә чыкты. Көзге чәчү дә тукталмады. Ике Т - 150 тракторлары ГД - 7 лущильниклары белән туфракны чәчүгә хәзерләүгә керештеләр.

Салам җыючылар да «тәнәфес» ясамадылар. Марс Шәйхиев, Рамил Сәхипов һ.б. сәнәкләрен тотып, уңышы җыелган басуга килделәр.

- Мондый төз, тигез кибәннәрне һичкайда күргән юк. Ничек шулай булдыра аласыз?- дип сораштык егетләрдән.

- Мидехәт оста бу эшкә,- диделәр безгә. - Ул тырышмаса, без генә булдыра алмыйбыз моны.

Мидехәт Дәүләтшин МТЗ - 80 тракторына тагылган салам төягеч агрегат белән эшли икән. Аннан - моннан гына эшләргә күнекмәгәнлеге кибәннәреннән күренә инде.

Кукуруз басуында эшләүчеләр дә яңгырны сәбәп итеп ял итәргә ашыкмадылар: иртән - иртүк силос базы янында иделәр инде алар. Ә Марат Шаһивәлиев өчен яңгыр ни дә, кояш ни: К - 700 тракторы белән баздагы массаны тыгызлапмы - тыгызлый.

Озак та үтмәде «ДОН - 680» комбайнчылары Рамил Гыйниятуллин белән Әхәт Зиннәтуллин да кукуруз урдыруга керештеләр. Яшел массаны траншеяга ташучы «КамАЗ»чылар Айрат Нургалиев, Әсхать Зәйдуллин, тракторчылар Ришат Атауллин, Ринат Мөхәрләмов, ГАЗ - 53 автомашинасын йөртүче Фаяз Мингалимов өчен эш фронты тудырырга кирәк бит.

- Әбәттән соң комбайннар да басуга кузгалды: табигатьтән мәрхәмәт көтеп, ял итеп ята торган вакыт түгел, дип уйлаганнардыр инде. Югыйсә «кыска тәнәфес» ясап алсалар да зур гөнаһ булмас иде. Ник дигәндә «Татарстан» хуҗалыгы уракта иң әйбәт эшләүче хуҗалык. Бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культураларны барлык мәйданнарның 71 процентында уңышын җыеп алдылар инде. Югыйсә, урып - җыю техникалары да күп түгел, өстәвенә әле искеләр дә. Ә инде җәһәт хәрәкәт итүләре тырышлыкларыннан, көн - төн белән санашмыйча эшләүләре белән тәэмин ителде. Әнә хуҗалыктагы бердән - бер булган «ДОН - 1500» хуҗасы Васыйл Гыйрфанов иң күп бөртек суктырып алучыларның берсе. Игеннәрне тезәмнәргә салуда Илнур Хәммәтвәлиев, Радик Минаповка тиңнәр юк.

Дөрес, МТСтан килгән 5 «КЕЙС»та саллы ярдәм күрсәтте хуҗалыкка. Уҗым һәм сабан бодаеның шактый мәйданын «ашыгыч ярдәм» отряды егетләре урып - җыйганнар.

- Август азагында урып - җыюны тулысынча тәмамлаячакбыз,- ди хуҗалыкның баш агрономы Әхәт Галиуллин,- аннары инде эшнең зур өлеше ындыр табагында булачак.

Ындыр табагы дигәннән, без хуҗалыкта булган көнне дә, һәр көндәгечә, кызу эш кайный иде биредә. Механикалаштырылган, шулай ук җирле ашлык чистарту агрегатлары ашлык эшкәрттеләр. Көндезге сменада эшләүче кызлар - мәктәп укучылары да көне буе әвәрә килделәр биредә. Ашлык дәүләткә дә озатылды, орлыкка да салынды, фуражга да аерылды. Ындыр табагына төнге сменага эшкә чыгачак пенсионер хатын - кызлар өчен дә эш шактый калган иде әле ул вакытта.

- Аның каравы, сентябрь аенда эш булмаячак биредә. Никадәр тизрәк эшләсәк, шулкадәр яхшырак,- диде безгә пенсиядә булуына да карамастан ындыр табагында эшне җитәкләүче Насыйх ага Йосыпов.

... Кичкә таба күк йөзендә болытның әсәре дә юк иде. Кычытканлы кырларындагы хезмәт шавы исә ярты төнгәчә сүнмәде.

**Р.ГИНЯЕВА.**

# Туңга сөрү туңга калмасын

## (агрокүзәтү)

Урып - җыю эшләре никадәр генә киеренке булса да, киләсе ел турында уйласак, туңга сөрүне һич тә икенче планга калдырырга ярамый. Әмма район буенча бу эшнең темпы канәгатьләнерлек түгел әле. Быел бу эшне 62 мең гектардан артык мәйданда башкарасы булса, кичәге көнгә фәкать 6354 гектар җир сөрелгән. Хәтта кукуруз һәм шикәр чөгендере җирләрен чигереп торганда да туңга сөрүнең барышы канәгатьләнерлек түгел. Дөрес, «Заветы Ильича», Мичурин исемендәге, «Таң», Кузнецов исемендәге, «Заря», «Рассвет», «1 нче Май» хуҗалыкларында, «Агрохимсервис» ярдәмче хуҗалыгында туңга сөреләсе мәйданнарның 15 - 20 проценты эшкәртелгән. Ә менә «Игенче», «Комбайн», «Татарстан», «40 лет Победы»да, нефтебаза һәм РСУның ярдәмче хуҗалыкларында туңга сөрелгән мәйданнар 100 гектарга да җыелмый, яки шул чама гына, ә «Үрнәк»тә әлегә 25 гектар гына мәйдан эшкәртелгән. Бу гаҗәп тә түгел, чөнки ул хуҗалыкларның күбесендә туңга сөрүгә бик аз санда гына техника тартылган, алары да нәтиҗәле файдаланылмый. Әйтик, «Татарстан», «40 лет Победы», «Үрнәк»тә туңга сөрүдә 1 - 2 ДТ - 75 тракторы гына эшли, алары да бер генә сменада. Югыйсә, Мичурин исемендәге, Кузнецов исемендәге, «Заря» хуҗалыкларында бу эштә 5 - 6 берәмлек техника катнаша һәм төнге смена да оештырылган. Ә менә МСОның ярдәмче хуҗалыгында, «Лесная поляна», Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкларда булган техникага, шул исәптән промышленность предприятиеләреннән ярдәмгә җибәрелгән тракторларга да эш фронты өлгертә алмыйлар. Берочтан, район җитәкчелеге күп кенә хуҗалыкларны киң алынлы француз сабаннары, үзебездәге сабаннарны калаклар белән тәэмин итү буенча да чаралар күрүен һәм туңга сөрүне туңнарга кадәр калдырмас өчен бар мөмкинлекне эшкә җигү зарурлыгын кабатларга туры килә. Сүз техниканы ике сменада эшләтү, бу уңайдан механизаторларны ашату мәсьәләсен дә хәл кылу, хуҗалыктагы барлык эшне энергия куәте зуррак тракторларны нәкъ менә туңга сөрүдә файдаланырлык итеп оештыру турында бара.

**● Җитди хәл**

## Булган, булган - ботка булсын,

диләр. Бу юлы сүз уҗым культуралары чәчү турында. Ул эштә төп шартларның берсе - орлыкларны җиргә минераль ашлама белән бергә күмдерү. Ә менә «Үрнәк» хуҗалыгында нәкъ шуны санга сукмыйлар булып чыкты. Хуҗалык быел уҗым культураларыннан ярыйсы ук уңыш алса да, районның уртача күрсәткеченә чыга алмауларын онытканнар, күрәсең. Шуңа күрә, чәчкән - чәчкән, җиренә җиткереп эшләргә кирәк иде инде.

## 73 нче ВПЧда - беренче юбилей

25 нче августта, 10 ел элек ТРның эчке эшләр министрлыгының янгынга каршы службасы идарәсе карары нигезендә Норлат шәһәрендә 73 нче ВПЧ оеша. Частьнең төп бурычы бик төгәл билгеләнә: Октябрь һәм Чирмешән районнарының нефть чыгару объектларын янгыннардан саклау. Бу авыл хуҗалыгында, шәхси секторда да янгыннардан саклау буенча бик мөһим мәсьәлә булып тора, нәкъ шул җәһәттән 73 нче ВПЧ янгынчылары зур булышлык күрсәтәләр дә. Бүген биредә куәтле 5 янгын машинасы исәпләнә, янгын частендә 86 кеше, шул исәптән 10 офицер эшли.

Коллективта зур оешканлык һәм объектларны уттан саклау өчен нык әзерлек хөкем сөрә.



### Россиянең сугышчан дан көннәре

# 23 август - совет гаскәрләре Курск сугышында немец - фашист гаскәрләрен тар - мар иткән көн

1943 елның 5 июленнән 23 августка кадәр барган Курск сугышы икенче Бөтендөнья сугышы тарихындагы иң зур көрәшләрнең берсе буларак тарихка керде. Ул сугышта ике яктан 4 миллионнан артык кеше, 69 меңнән артык орудие, миномет, 13 меңнән күбрәк танк һәм үзйөрешле орудие, 12 меңләп самолет катнашты. «Техниканың күплеге, хәрәкәтләрнең тыгызлыгы ягыннан Курск сугышына тиңнәр юк»,- дип язды В.К.Рокоссовский.

1942 - 43 елгы кышкы сугышлар нәтиҗәсендә көнбатышка таба бик эчкәре сугышкан Курск дугасы барлыкка килә. Килеп туган хәлне искә алып, немец - фашист командованиесе төньяктан Орел ягыннан һәм көньяктан Белгород ягыннан Курскка таба кара - каршы удар ясап, совет гаскәрләре группировкасын чорнап алырга һәм шуның белән Мәскәүгә юл ачарга карар кыла.

Дошманның ниятен сизеп, совет командованиесе алҗыткыч оборона сугышларында дошманны хәлсезләндерү, аның техникасын юкка чыгару, шуннан соң контрһөҗүмгә күчү һәм фашист гаскәрләренең удар группировкаларын тар - мар итеп бетерү максатыннан Курск чыгынтысында күрә торып оборонага күчәргә карар итә. Гитлер командованиесе «Цитадель» дигән һөҗүм операциясе эшли. Гитлер һөҗүмне 5 июль иртәсендә башларга карар бирә.

Совет командованиесе «Цитадель» операциясенең ниятен генә сизеп калмый, ә разведка мәгълүматлары буенча дошман гаскәрләренең кайсы көнне һәм сәгать ничәдә һөҗүмгә күчәсен дә ачыклый. Һәм алардан алданрак кузгалырга карар ителә. Һөҗүмгә кузгалырга хәзерләнеп торган дошман өстенә 2460 орудие, миномет һәм «Катюша»лар ут яңгыры коя башлый, авиация бомба ударлары ясый. Үзәк (В.К.Рокоссовский) һәм Воронеж фронтлары (И.Ф.Ватутин) гаскәрләре контрһөҗүмгә күчәләр. Каты сугыш башланып китә. Гитлерчылар яңа «Тигр», «Пантера» танкларын, үзйөрешле «Фердинанд»ларны сугышка кертеп берничә мәртәбә өстенлек алырга тырышып карыйлар. Әмма алар һәммәсе дә уңышсызлыкка очрый.

Совет гаскәрләре бөтен фронт буйлап гомуми контрһөҗүмгә күчәләр. Безнең гаскәрләр, дошманның ныклы каршылыгын җиңә барып, 5 августта Орел һәм Белгородны азат итәләр. Бу җиңү хөрмәтенә Ватаныбыз башкаласы Мәскәүдә Бөек Ватан сугышы тарихында беренче тапкыр 120 орудиедән салют бирелә.

Аннан соңгы һөҗүмгә Брянск, Степной фронтлары гаскәрләре дә кертелә. Дошман күп югалтулар белән чигенә. 23 августта Харьков шәһәре азат ителә. Шуның белән безнең гаскәрләрнең Курск дугасындагы сугышы тәмамлана. Совет гаскәрләре дошманның 30 дивизиясен, шул исәптән 7 танк дивизиясен юк итәләр. Дошман 500 меңнән артык сугышчысын югалта.

Курск янында немец - фашист гаскәрләрен тар - мар итү бөтендөнья - тарихи әһәмияткә ия вакыйга була.

**Язманы И.САНДЛЕР әзерләде.**

# Котлыйбыз!

*Гаилә дустыбыз **Илдус Каюм улы Җамаловны** 50 яшь тулу белән тәбриклибез.*

*Гел шатланып яшә, хәсрәт күрмә,*
*Тыныч булсын һәрчак күңелең.*
*Бәрәкәтле матур тормыш сиңа*
*Алып килсен киләчәк гомерең.*

***Лотфуллиннар һәм Сатдаровлар гаиләсе.***

---

Хөрмәтле торыш иптәшем, әтиебез **Илдус Каюм улы Җамаловны** 50 яшь тулган көне белән чын күңелдән тәбрик итәбез.

Котлы булсын туган көнең
Озак яшә, бул син бәхетле.
Исәнлегең, тынычлыгың булса гына
Таба алырсың олы бәхетне.

**Иң изге теләкләр белән тормыш иптәшең Фәния, улың Илмас, кызың Гөлназ.**

# Дарусыз дәвалану



***«Магнитлы доктор»** сезнең барлык төр чирләрегездән да дәвалаячак, кәефегезне яхшыртачак.*

Байтак кешене магнит клипсылары баш авыртуыннан коткарачак. Алар 20 минут эчендә кан басымын .нормальләштерә, һава торышы кискен үзгәргәндә ярдәм итә, ару - талуны баса.

Әгәр дә сез ашказаны - эчәк, бөер, урологик, гинекологик чирләрдән җәфа чиксәгез сезгә магнитотрон ярдәмгә киләчәк. Ашар алдыннан магнитлы көпшәдән 100 грамм су эчсәгез ул гастрит, бөердә таш һәм алда әйтелгән чирләр булганда профилактик һәм дәвалау эффекты күрсәтәчәк, шулай ук организмның чиргә каршы тору сәләтен арттыра, йокысызлык чиреннән арындыра.

Яңалык! Магнитлы беләзек - арыганлыкны, стрессны бетерә торган чара, йөрәк эшчәнлеген һәм артериаль басымны тотрыкландыра, иммун системасын активлаштыра, йокыны һәм эчке органнар эшчәнлеген нормальләштерә.

Магнитотрон - 1 (ректаль) хроник простатитны, ир - атлар кысырлыгын, эрекция бозылуны, гемморойны кисәтә.

Магнитотрон - 2 (вагиналь) хатын - кызларның фригидлыгын, ялкынсыну, эррозия, менструаль циклның бозылуы, климакс белән бәйле неврозлар вакытында ярдәмгә килә.

«Биомаг» магнитлы олтырагы - 2 арыганлыкны, аяклар шешенүен бетерә, иммун системасын активлаштыра. Аякларда гөмбәчекләр чыкканда, тромбофлебит, веналар киңәюендә ул сезне чирдән коткарачак. Ә бәлки «Биомаг» терелүгә өметсез чакта соңгы шанс булып киләдер әле.

Томау төшүдән, өске сулыш органнары авыртудан, гаймориттан сезне лор - клипсылар коткара.

Магнитлы билбау (аппликатор) сезне радикулиттан, остеохондроздан, ревматизмнан коткарачак, буыннарны хәрәкәтләндерәчәк һәм фармокологик препаратлардан баш тартырга мөмкинлек бирәчәк.

Барлык магнитотроннар да клиник сынаулар үтте. РФ Сәламәтлек министрлыгы аларның куллану мөмкинлегең киңлеген раслады.

Аларны серияле җитештерү рөхсәт ителде. Дәвалау тәэсире 10 елга җитә «Градиен - магнитотрон» фәнни - тикшеренү институты түбәндәге магнитотроннар тәкъдим итә:

Магнитлы билбау - 30 мең сум

Магнитлы көпшә - 25 мең сум

М - 1 (ректаль) - 15 мең сум

Магнитлы клипсалар - 15 мең сум

Лор клипсалар - 15 мең сум

Беләзек - 30 мең сум

«Биомог» олтырагы - 40 мең сум.

Сәүдә - күргәзмә 26 август (сишәмбе) көнне район үзәк поликлиникасының 1 нче катындагы холлында, сәгать 11дән 12гә кадәр уздырылачак.

Лицензия номеры 30 - 03/404 (1996 елның 6 июленнән).

Лицензия РФның барлык территориясендә дә гамәлдә.

# Авылда бартер



«Кондырча» КХАсы шоферы караңгы төндә «ЗИЛ - 130» машинасына солы капчыгы сала да урларга җыена. Дөрес, ул уяу ДАИ хезмәткәрләре тарафыннан туктатыла. Нәтиҗәдә урланган кире кайтарыла, абруй югала, ә җәзадан котылу юлы юк.

Авылда бүген иң мәшәкатьле чак. Август һаман да искәртә тора: игенче ашык, өлгергән башаклар артык көтмәячәк. Ындыр табаклары ашлык белән тула, машиналар элеваторга «йөгерә». Кызганычка каршы, әле авылда да җәмәгать байлыгы белән кул җылытучы - нинди авырлыклар белән үстергән игенне сакчылары булмаудан файдаланып урлаучылар бар икән әле. Ләкин, хокук саклау органнары уяу бу көннәрдә: төнге рейдлар, «Уңыш - 97» операцияләре ДАИ патрульләре тикшерүен оештыралар. Бу бурлыклар исемлеге Каравыл Тавы (Кузнецов исемендәге КХА) авылында 4 авылдашның 32 килограмм бөртек урлау фактыннан башланды. «Икмәк эшен» икәү планлаштыралар, икесе башкаралар. Урланган товарны тиз арада аракыга алмаштырырга өлгерәләр. Озак та үтми каракларның кемлеге ачыклана.

13 августта МСО ярдәмче хуҗалыгыннан да ашлык югалуы ачыклана. Биредә берәү эчкечелек белән шөгыльләнеп рәтләп эшләми дә, 163 килограмм бөртекне аракыга алмаштыра. Табигый ки, бурны җәза көтә. Шул ук көнне

Озын куллылар бернидән тайчанмыйлар. Шулай, Богдашкино авылында яшәүче слесарь, механизатор һәм каравылчы фермадан 4 дуңгыз баласын башка авылдашларына тәкъдим итәләр. Түләүгә саранланмый тегесе - 3,5 литр көмешкәсен бирә. Район эчке эшләр бүлеге хезмәткәрләре эзләренә төшеп аларга ерак китәргә ирек бирмиләр. Ә менә «Алга» КХАсыннан урланган дуңгыз балалары Алексеевск районының Биләр поселогында табыла. Колбай морасалы изге чишмәдән берәр нәрсә алгандырмы, юкмы анысы мәгълүм түгел, менә җәзасын алачагы көн кебек ачык. «Чирмешән» КХАсы җәйге лагерена да караклар табигать күрергә төшмиләр, ә баеп калмакчы булалар. Бу кампаниядә ике сарык урлана.

КХА җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп шуны гына искәртәсе килә: йозакларыгыз «юри генә» элмәгәнме? Тикшерегез. Нәтиҗәсен күрерсез.

**Т.КОНСТАНТИНОВА.**



# Түбәдән су үтә

*Сезгә Мәктәп урамының 29 нчы йортында яшәүчеләр яза. Безнең йорт - АТП карамагында. Без монда 1984 елдан бирле яшибез һәм йортның түбәсеннән барлык фатирларга һаман яңгыр үтә. АТП җитәкчелегенә телдән дә, язмача да берничә мәртәбә мөрәҗәгать иттек тә, йортка күчкәннән бирле ни агымдагы, ни капиталь ремонт үткәрелгәне юк. «Өй түбәсенә менеп биемәсәгез су үтмәс»- дип җавап бирделәр безгә.*

*Озакламый көз җитә, яңгырлар китәчәк. Шулай итеп без фатирларыбызда тагын «йөзәргә» тиешме икәнни?*

*Йорт халкы исеменнән*

**Е.ПЕТРОВА.**
**Норлат шәһәре.**

# Белдерүләр




## Сатабыз

**«Сюита» пианиносы.** Тел.: 5 - 23 - 67.

***

## Сатып алабыз

**«Б» категорияле «Татнефть», «Лукойл», «Сургут», «ПУР», «Газпром», «Когалым», «Юганскнефтегаз» акцияләрен.** Тел.: 5 - 37 - 69. Лицензия № 747.

## Төзибез

**Йорт, гараж, сарайлар. Тиз һәм кыйммәт түгел.** Тел.: 2 - 27 - 60. Шакирны сорарга.

***

## Эшкә чакырабыз

**Октябрь районы торак - коммуналь хуҗалыгы МППсына IV - V разрядлы слесарь - сантехниклар, электр һәм газ белән эретеп ябыштыручылар кирәк.** Кадрлар бүлегендә тел.: 2 - 10 - 98, 2 - 21 - 71.



БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**

МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

**"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.**

**Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы, 19.**

**Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия, реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.**

***Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.***

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2334 данә.